

1817 елда алман профессоры барон Карл фон Дрез из Карлсруэ този, ә 1818 елда беренче ике копчәкле самокат патентлана, аны ул “йогерv машинасы” дип атый (Laufmaschine).
Дреза самокаты ике копчәкле, агач рульле, башка торле педальле иде, дип билгеләмә бирә Wikipedia. Бу профессорга уйлап табулары очен, бигрәк тә авылныкылар рәхмәт әйтә.
Бvген барлык авылларда велосипед - кешеләренен тормышынын аерылгысыз олеше. Бала аякка басуга, әти-әнисе ана велосипед сатып ала – бу шундый зур бәхет, әйтеп бетереп булмый! Һәм менә ул башта оч копчәкле, аннары ике копчәкле велосипед педальларына таянып, бу тормышны “әйләндерә” башлыйлар. Шулай, тормышта бу тор транспорт һәйкәлләр куярдый урын алып тора. Һәм Ельникнын Заречный урамында яшәvче ое алдына шундый (рәсемдә) vзенчәлекле һәйкәл куйган.
Велосипедта йорv - спорт кына тvгел, ә зур ләззәт, бигрәк тә жәйге вакытта. Тик авылда кышын да велосипедта йоргәннәрен кvрергә була, мәсәлән, хатын-кызлар тиз генә кибеткә ипигә чаба ала.
Кадошкино районынын “Возрождение” газе-тасы язмаларынын берсендә лаеклы ялда булган актив кеше - Наилә Исмагыйль кызы Янбулатованы велосипедта кvрдем. Ул - лаеклы ялда булган актив кешеләрнен берсе. Алар белән сокланмый момкин тvгел, чонки бу кешеләр пенсиягә чыккач та тулы тормыш белән яшәргә момкин булуын һәрвакыт раслыйлар. Үз тормышынны якты, бай, кызыклы, мәгънәле итv теләге булу пенсиядә чакта бик актуаль.



Наилә Исмагыйль кызы Янбулатова - 13 ел стажлы һәм бары тик актив тормыш позициясе булган пенсионер. Хәзер ул ой хужалыгын алып бара; яз һәм жәй айларында

бакчада, йорт тирәсендә чәчәкләр утырта, хужалык эшләре белән шогыльләнә. Кечкенәдән теләсә нинди ой эшләрен башкарырга ойрәнгән. Ун-ике яшеннән Исмагыйль кызы Наилә кибеттә сатучы булып эшләгән әнисенә жыештырыр-га булыша. Большие Поляны урта мәктәбенен унынчы сыйныфын тәмамлагач, Саранск кооператив техникумына укырга керә. Ә аны тәмамлаганнан сон, туган авылына кайта. 1972 елда Наиль Хосәен улы Янбулатовка кияvгә чыга. Бер елдан яшь гаилә Кадошкино бистәсенә кvчеп килә. Тагын бер елдан сон аларнын кызлары Светлана туа. Ә 1975 елда Наилә Исмәгыйль кызы Кадошкино электротехника заводына эшкә урнаша, анда лаеклы ялга чыкканчы ашханә модире булып эшли. 1978 елда улы Дамир туа. Ә хәзер балаларынын vз балалары бар. Наилә Ис-магыйль кызынын оч оныгы vсә. Балалары, гаиләләре белән каникулларга, озын яллар вакытында Мәскәv белән Санкт – Петербургтан киләләр.
- Без ирем белән ботен яшьлегебезне балалар тәр-бияләvгә һәм электротехника заводында тырышып эшләvгә бирдек. Ирем башта машина йортvче буларак рейсларга йорде, аннан озак вакытлар завод житәкчесен йортте. Хәзер ул да лаеклы ялда. Балалар һәм оныклар безгә һәрчак ярдәм итә. Без аларга барысы очен дә рәхмәтле һәм алар белән горурланабыз. Улым хәрби, оныгым да анын юлыннан бара. Тагын бер оныгым Мәскәvдә дипломатик кадетлар корпусында укый, - дип сойли vзенен гаиләсе турында Наилә Исмагыйль кызы Янбулатова.
- Безнен заводта ашханә зур иде. Ботен район vзәгендә шундый зур бердән-бер булды. 120 урынга кадәр хезмәт кvрсәтә идек. Без ике смена эшләдек: ике пешекче, зал һәм кухня хезмәткәрләре, савыт-саба юучы. Хезмәттәшләрем кvп иде - Надежда Трохина, Нина Лапаева, Мария Лобанова һәм башкалар. Без дус идек һәм хәзер дә аралашабыз. Ашханә хезмәткәрләре һәрвакыт ризыкны тәмле һәм туклыклы итеп пешерергә тырыштылар; безнен эшебезне гел әйбәт дип бәяләделәр. Ихлас кvнел белән эшләдек, коллектив та тату иде. Ә мона, vзегез беләсез, кvп нәрсә бәйле, - дип искә ала язма героебыз.
Кvпьеллык һәм намуслы хезмәте очен Н.И.Янбулатовага район башлыгы берничә тапкыр Рәхмәтен белдерә, Мордовия Дәvләт Советынын Мактау грамотасы белән бvләкләнә. Эшләгән вакытында завод хорында да жырлый Наилә Исмаил кызы. Әлбәттә, балаларны тәрбияләv белән эштән тыш, йорт хужалыгы да кvп вакыт ала иде. Ике сыер, vгез, кvркә, тавыклар, vрдәкләр, казлар кvп асрыйлар.... Бакча. Хәзер инде бу кадәр эш юк. Тавыклары гына калган аларнын. Йорт янында буада - балык. Әмма хоббие - чәчәкләр vстерvе vзгәрешсез кала. Хужабикәнен бакчасы, тирә-ягы чәчәккә кvмелгән.
Актив кеше, гомере буена актив инде. Узган ел Наилә Исмәгыйль кызы скандинавия йореше белән иптәшләре Раисә Зверовщикова, Валентина Агафонова һәм Раисә Климова белән шогыльләнгән. ФОКта аларга махсус таяклар биргәннәр, һәм алар стадион һәм Кадошкино бистәсе буйлап йоргәннәр. Наилә Исмәгыйль кызы даими рәвештә авыл бренды булган велосипедта йорде, ә хәзер яна транспорт торе- самокатка кvчеп утырды. Балалары туган коненә бvләк иткәннәр, ул электр утына утыра да китә, рәхәт, аягын авыртуын да сизмисен! Наилә vзенен транспортыннан аерылмый, анын белән ботен жирдә - азык-толек кибетенә дә, банкка да, коммуналь тvләvләр буенча квитанцияләр тvләv очен дә, гомумән, һәр эш буенча да хезмәт ветераны йори.

**Наилә НАСЫРОВА**